КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 22 гыйнвар г.Казань № 30

2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2026 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында 15 997 684,7 мең сум күләмендә юл эшләре программасын;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 000 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 480 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 1 396 600,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2026 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 11 342 603,2 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 4 195 209,5 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2026 елга «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче

программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 1 125 006,9 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 416 098,5 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2026 елга Татарстан Республикасының терәк торак пунктларында юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән программаны 8 000 000,0 мең сум күләмендә;

2026 елга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләренә керү юлларын капиталь ремонтлауга, ремонтлауга юнәлдерелгән 300 000,0 мең сум күләмендәге программаны;

2027 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында 23 340 885,7 мең сум күләмендә юл эшләре программасын;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 000 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 480 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 1 396 600,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2027 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 13 538 614,6 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 6 668 272,9 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2027 елга «Авыл территорияләрен комплекслы үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган

каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 349 388,6 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 172 087,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2028 елга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларында 22 085 006,6 мең сум күләмендә юл эшләре программасын;

2028 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Казан шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексды үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 2 000 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2028 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Чаллы шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексды үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 1 360 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2028 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында Түбән Кама шәһәр агломерациясенең транспорт инфраструктурасын комплексды үстерү буенча Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 480 000,0 мең сум күләмендә финанслана торган программаны;

2028 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында төбәк яки муниципальара әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юнәлдерелгән, 1 396 600,0 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2028 елга «Тормыш өчен инфраструктура» илкүләм проекты кысаларында автомобиль юлларын һәм ясалма юл корылмаларын норматив хәлгә китерүгә юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 12 762 263,6 мең сум күләмендә субсидия рәвешендә кергән акча һәм 8 159 480,1 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2028 елга «Авыл территорияләрен комплексды үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасындагы «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәреннән авыл торак пунктларының иң якын иҗтимагый әһәмиятле объектларына, шулай ук авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм эшкәртү объектларына алып бара торган каты өслекле гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү һәм реконструкцияләү чараларын тормышка ашыруга юнәлдерелгән, федераль бюджеттан 779 340,2 мең сум күләмендә субсидияләр рәвешендә кергән акча һәм 498 266,7 мең сум күләмендә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән финанслана торган программаны;

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

2026 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең гомуми суммасы 46 613 202,8 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

2027 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең гомуми суммасы 49 305 848,8 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

2028 елга Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы юлларында юл эшләренең гомуми суммасы 49 520 957,2 мең сум тәшкил итә дип билгеләргә.

3. Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларда муниципаль юл эшләре программаларын гамәлгә ашыруга җибәрелә торган муниципаль юл фондларының ассигнованиеләре күләме турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре тәкъдимнәрен кабул итәргә:

2026 елга 1 нче кушымта нигезендә 1 901 024,9 мең сум күләмендә;

2027 елга 2 нче кушымта нигезендә 1 963 924,5 мең сум күләмендә.

2028 елга 3 нче кушымта нигезендә 1 993 691,2 мең сум күләмендә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 - 2027 елларга Татарстан Республикасында гомуми файдаланудагы юлларда юл эшләре турында» 2025 ел, 19 июль, 534 нче номерлы карарының 1 пунктындагы унберенче – егерме өченче абзацларны, 2 пунктындагы дүртенче һәм бишенче абзацларын, 3 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин